# Күңелле балачак

1) Сибә кояш нурын безгә
Балкытып барыр юлны.
Килдек тормышны бизәргә
Тотынып кулга-кулны.

Кушымта: Күңелле безнең балачак
Без - замана баласы.
Алдагы тормышны бизәп
Зур-зур юллар саласы.

2) Чулпан йолдыз юл күрсәтә
Яктырта безнең эзне.
Киләчәктә илебездә
Зур эшләр көтә безне.

3) Гаиләгә рәхмәтле без
Алар безгә зур терәк.
Балкысын уңышларыбыз,
Бездән булыр ул - бүләк.